| СОВЕТ БАВЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ |
|---|---|---|

| **РЕШЕНИЕ** | | **КАРАР** |
|---|---|---|
| 29.05.2020 | Баулы шәһәре | № 265 |

Татарстан Республикасы “Баулы муниципаль районы” муниципаль берәмлеге муниципаль милегендә булган муниципаль мөлкәттән һәм җир участокларыннан, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы территориясендә дәүләт милке чикләнмәгән җир участокланыннан файдаланган өчен аренда түләве һәм пеня буенча бурычларны түләттерү өметсез дип тану һәм юкка чыгару тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 47.2, 160.1 статьялары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы «Баулы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Әлеге карарга 1нче кушымта нигезендә Татарстан Республикасы “Баулы муниципаль районы” муниципаль берәмлеге муниципаль милегендә булган муниципаль мөлкәттән һәм җир участокларыннан, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы территориясендә дәүләт милке чикләнмәгән җир участокланыннан файдаланган өчен аренда түләве һәм пеня буенча бурычларны түләттерү өметсез дип тану һәм юкка чыгару тәртибен расларга.

2. Баулы муниципаль районы башкарма комитетына һәм «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы» МКУга Татарстан Республикасы "Баулы муниципаль районы" муниципаль берәмлеге муниципаль милегендә булган муниципаль мөлкәттән һәм җир участокларыннан, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы территориясендә дәүләт милке чикләнмәгән җир участокланыннан файдаланган өчен аренда түләве һәм пеня буенча бурычларны түләттерү өметсез дип тану һәм юкка чыгару буенча комиссия төзү эшен оештырырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы муниципаль районы Советының санитар-экологик иминлек һәм табигатьтән файдалану мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Баулы муниципаль районы Башлыгы,
район Советы Рәисе

АППАРАТ СОВЕТА / СОВЕТ АППАРАТЫ

Р.Х. Гатиятуллин

Татарстан Республикасы Баулы
муниципаль районы Советының
2020 елның 29 нчы май
265нче номерлы карарына
1нче кушымта

Татарстан Республикасы “Баулы муниципаль районы” муниципаль берәмлеге муниципаль милегендә булган муниципаль мөлкәттән һәм җир участокларыннан, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы территориясендә дәүләт милке чикләнмәгән җир участокланыннан файдаланган өчен аренда түләве һәм пеня буенча бурычларны түләттерү өметсез дип тану һәм юкка чыгару
тәртибе

1. Әлеге Тәртип Россия Федерациясе Бюджет кодексының 47.2 статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында карарлар кабул итү тәртибенә карата гомуми таләпләр турында» 2016 елның 6 маендагы 393 номерлы карары нигезендә эшләнде һәм Татарстан Республикасы “Баулы муниципаль районы” муниципаль берәмлеге муниципаль милегендә булган муниципаль мөлкәттән һәм җир участокларыннан, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы территориясендә дәүләт милке чикләнмәгән җир участокланыннан файдаланган өчен аренда түләве һәм пеня буенча бурычларны түләттерү өметсез дип тану һәм юкка чыгару тәртибен билгели.

2. Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы муниципаль милегендә булган муниципаль мөлкәттән һәм җир участокларыннан, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы территориясендә дәүләт милке чикләнмәгән җир участокланыннан файдаланган өчен аренда түләве һәм пеня буенча бурычлар, аерым арендаторларда исәптә булганда, түбәндәге очракларда түләтелүгә өметсез дип таныла һәм бетерелелә:

1) Физик зат - бюджетка түләүләр түләүченең үлеме яки аны Россия Федерациясе Граждан процессуаль законнарында билгеләнгән тәртиптә вафат дип тану очрагында;

2) «Бөлгенлек (банкротлык) турында» 2002 елның 26 октябрендәге 127-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, шәхси эшмәкәрне – бюджетка түләүләр түләүчене, бюджетка түләүләр буенча бурыч өлешендә, бурычлының мөлкәте җитмәү сәбәпле банкрот дип тану;

3) оешманы - бюджетка түләүләр буенча бурыч өлешендә бюджетка түләүләр түләүчене, оешманың мөлкәте җитәрлек булмау һәм (яки) әлеге оешманың гамәлгә куючылары (катнашучылары) тарафыннан Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән чикләрдә һәм тәртиптә аларны түләү мөмкинлеге булмау сәбәпле бетерү;

4) судның бюджет керемнәре администраторы бюджетка бурычларны түләттерү мөмкинлеген юкка чыгарган акт кабул итүе (аны түләттерүнең билгеләнгән срогы (дәгъва вакыты) тәмамлануга бәйле рәвештә), шул исәптән бюджетка түләүләр буенча бурычларны түләтү турында судка гариза бирү срогының юкка чыгуын кире кайтарудан баш тарту турында суд карары чыгару;

5) «Башкарма производство турында» 2007 елның 2 октябрендәге 229-ФЗ номерлы Федераль законның 46 статьясындагы 1 өлешенең 3 һәм 4 пунктларында каралган нигезләр буенча башкарма производствоны тәмамлау турында суд приставы-башкаручы карар чыгарганнан соң, әгәр бюджетка түләүләр буенча бурыч биш елдан артык булган булса, түбәндәге очракларда:

бурыч күләме бөлгенлек турындагы эш кузгату өчен бурычлының бөлгенлек (банкротлык) турында Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән таләпләр күләменнән артмаса;

суд бюджетка түләүчене банкрот дип тану турында гаризаны кире кайтарса яки, банкротлык турындагы эштә кулланыла торган процедураларны үткәрү өчен суд чыгымнарын каплау өчен җитәрлек акча булмау сәбәпле, банкротлык турындагы эш туктатылса.

3. Бурыч район бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында махсус төзелгән комиссия карары нигезендә өметсез дип танылa һәм «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Мөлкәт

һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» МКУ күрсәтмәсе нигезендә исәптән төшерелә.

4. Муниципаль район бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләттерүгә өметсез дип тану һәм аны исәптән төшерү турында карарлар кабул итү өчен нигезләрнең булуын раслаучы документлар:

- муниципаль район бюджетына түләүләр буенча бурычларның исәпкә алына торган суммалары турында керемнәр администраторының хисапларыннан өземтә;

- муниципаль район бюджетына түләүләр буенча бурычларны тәэмин итү буенча күрелгән чаралар турында керемнәр администраторының белешмәсе.

4.1. Муниципаль район бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләттерүгә өметсез дип тану өчен шартларны раслаучы документлар:

1) физик затның үлүен таныклаучы яисә физик затны вафат дип игълан итү фактын раслаучы документлар;

2) шәхси эшмәкәрләрнең Бердәм дәүләт реестрыннан, муниципаль район бюджетына түләүләр түләүче индивидуаль эшкуарны банкрот дип тану нәтиҗәсендә, эшчәнлекне бетерү турында мәгълүматны, Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан, муниципаль район бюджетына түләүләр түләүче оешманы бетерү белән бәйле, эшчәнлекне туктату турында мәгълүматларны үз эченә алган документ;

3) бурычны түләттерүнең билгеләнгән срогы (дәгъва вакыты) тәмамлануга бәйле рәвештә, бюджет керемнәре администраторы бюджетка бурычларны түләттерү мөмкинлеген юкка чыгарган суд акты, шул исәптән бюджетка түләүләр буенча бурычларны түләтү турында судка гариза бирү срогының юкка чыгуын кире кайтарудан баш тарту турында суд карары;

4) «Башкарма производство турында» Федераль законның 46 статьясындагы 1 өлешенең 3 һәм 4 пунктларында каралган нигезләр буенча башкарма документны түләттерүчегә кире кайтарганда башкару эшләрен тәмамлау турында суд приставы-башкаручының карары;

5) башка документлар.

5. Боерык күчермәсе, боерык кабул ителгән көннән 10 көн эчендә, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына җибәрелә.

6. Бурычларны бетерү турында карар аерым арендалаучылар арасында булган бурычларга карата кабул ителә.

7. Бурычларны исәптән төшерү белән бәйле үзгәрешләр җирле үзидарә органының финанс хисабына карар кабул ителгән айдан соң килүче айның беренче числосына кертелә.